ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 ноябрь, 2020 ел № 2/5

2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль
милкен хосусыйлаштыру Фараз планын
(программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) кушымтага нигезләнеп расларга.
2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының 2/5
Карарына кушымта
17 ноябрь, 2020 ел

**2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планы (программасы)**

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планы (программасы, алга таба – Фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә туры китереп эшләнгән.

2. 2021 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, шәһәр бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлтелгән.

3. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә туры китереп, законда каралган ысуллар белән башкару күздә тотыла.

2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

4. 2021 елда муниципаль казнада торган һәм муниципаль предприятиеләрдә, учреждениеләрдә файдалануда булмаган күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

5. Хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге түбәнге таблицада күрсәтелгән:

| № | Объект исеме | Урыны | Капиталь төзелеш обектының мөйданы/озынлыгы | Җир участогы мәйданы | Фаразланган хосусыйлаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Суднолардан фекаль агынтыларын кабул итү өчен 16:52:010302:130 кадастр номерлы причал | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Аскы бьеф, Кама елгасының | 123 м | | I квартал |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сулъяк яры | | | |
| 2 | 16:52:030203:100 кадастр номерлы җир участогы һәм әлеге участокта урнашкан 16:52:030203:92 кадастр номерлы торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Спартаковская урамы, 6 йорт | 273,4 кв.м | 1 171 кв.м | I квартал |
| 3 | Ремонтный юлы, 25 йорт адресы буенча урнашкан база җир участогы белән, 16:52:100301:260 кадастр номерлы җир участогы. Капиталь төзелеш объектлары, шул исәптән: | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Ремонтный юлы, 25 йорт | 2083,3 кв.м | 5 501,0 кв.м | I квартал |
| 3.1. | 16:52:020701:3450 кадастр номерлы КПП янкормасы | | 41,10 кв.м | | |
| 3.2. | 16:52:020701:3476 кадастр номерлы склад №1 | | 144,80 кв.м | | |
| 3.3. | 16:52:020701:3477 кадастр номерлы машиналар гаражы | | 99,40 кв.м | | |
| 3.4. | 16:52:020701:3478 кадастр номерлы склад бинасы | | 651,80 кв.м | | |
| 3.5. | 16:52:020701:3390 кадастр номерлы янкорма | | 40,10 кв.м | | |
| 3.6. | 16:52:020701:3479 кадастр номерлы гараж | | 631,40 кв.м | | |
| 3.7 | 16:52:020701:3284 кадастр номерлы склад №2 | | 474,70 кв.м | | |
| 4 | 16:52:020128:1939 кадастр номерлы җир | Татарстан Республикасы, | | 257,0 кв.м. | I квартал |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | участогы һәм әлеге җир участогында урнашкан капиталь төзелеш объектлары, шул исәптән күчемсез милек объектлары: | Яр Чаллы шәһәре, Үзәк урам, 78А йорты, 78/А/1 йорты | 102,1 кв.м | | |
| 4.1. | 16:52:020128:178 кадастр номерлы склад | | 25,1 кв.м | | |
| 4.2. | 16:52:020128:194 кадастр номерлы склад | | 77,0 кв.м | | |

6. 2021 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиеләре:

| № | Предприятие исеме | Икътисадый эшчәнлекнең төп төре |
|---|---|---|
| 1 | «Автозавод идарәче компаниясе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиесе | Хезмәт өчен түләү яйсә шартнамә нигезендә күчемсез милек белән идарә итү |
| 2 | «Комсомол идарәче компаниясе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиесе | Хезмәт өчен түләү яйсә шартнамә нигезендә күчемсез милек белән идарә итү |
| 3 | «Үзәк идарәче компаниясе» Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиесе | Хезмәт өчен түләү яйсә шартнамә нигезендә күчемсез милек белән идарә итү |

7. Муниципаль милектә булган акцияләрне 2021 елда хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

8. Күчемсез милекне хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру шартлары турында, шул исәптән, милекне тартып алу белән бер үк вакытта мондый милекне сатып алучы затка сату башкарылганда, әлеге милек биләгән һәм аннан файдалану өчен зарури булган җир участогын хосусыйлаштыру шартлары турында карар Шәһәр Советы Карарлары нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

9. 2021 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлегенә Фараз планының гамәлдәге вакытында Шәһәр Советы Карарлары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.